# Татар халык табышмакларында сыйфат дәрәҗәләре

**Табышмак-күмәк эчендә берең әйткәннең мәгънәсен икенче кешедән чишелешен таптыру өчен генә башкарыла торган фольклор. Эзләп табылырга тиешле билгесез нәрсәне төрле яктан характерлауда аеруча сыйфат сүз төркеме киң кулланыла . Аның 4 дәрәҗәсе дә татар халык табышмакларында киң кулланыш тапкан.**

# Төп дәрәҗәдәге сыйфат

**бернинди өстәмә кушымча алмый:**

*1.**Ак** ябалак **ак** киезгә ятыр. (Кар)*

*2.**Озын** буйлы, **зәңгәр** күзле. (Җитен)*

*3.**Йомры, йомшак сары** йомгак Йөгереп йөри чирәмдә.(Чеби)*

# Артыклык дәрәҗәсе ясалу юллары:

***1) Беренче иҗеккә җайлаштырылган көчәйткеч кисәкчәләр ярдәмендә:***

Үзе **кып**-кызыл, күлмәге **ямь**-яшел. (*Карбыз*)

**2) иң, үтә, җете, дөм,чем кебек кисәкчәләр ярдәмендә:**

***Чем** кара - елан түгел, мөгезле - сөзгәк түгел, канатлы - песнәк түгел, очканда мыш-мыш килә, туфракка яререна, бу нәрсә, йә, кем белә? (Ат коңгызы).*

# Чагыштыру дәрәҗәсе –рак/-рәк кушымчасы ярдәмендә формалаша:

1. *Ачыдан ачы**рак**, татлыдан татлы**рак**, усалдан усал**рак**, дөрестән дөрес**рәк** нәрсә бар дөньяда? (Тел)*
2. *Кече**рәк** кенә күл эчендә дөрли-дөрли ут яна, уты суны киптерми, суы утны сүндерми. (Самавыр)*

**Кимлек дәрәҗәсе –гылт/-гелт, -кылт/-келт, -сыл/-сел, -су, -елҗем, -сел,-кылтым/-келтем, -ча, -мса кушымчалары ярдәмендә формалаша:**

***Үзе түгәрәк, урыны түрдәрәк, эче тулы күзәнәк; әчкелтем дә төчкелтем, бар нәрсәдән дә кадерлерәк. (Икмәк).***

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.